**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты карары**

**25.01.2018 ел** **№ 26**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында**

“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 14 июнендә “Татарстан Республикасының Бердәм тариф челтәре нигезендә хезмәт өчен түләү исәпләнгән дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турындагы” 477нче карарына үзгәрешләр кертү турындагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 29 декабрендәге 1123нче карарына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 5 февралендәге “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Бердәм тариф челтәре нигезендә хезмәт өчен түләү исәпләнгән муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турындагы (Татарстан Республикасы Кама Тамагы ммуниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 29 октябрендәге 436 номерлы, 2016 елның 7 июлендәге 473 номерлы, 2017 елның 4 сентябрендәге 814 номерлы карарларына кертелгән үзгәрешләр белән) карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 1 абзацның 1 пунктындагы “2015 елның 1 октябреннән” сүзләрен “2018 елның 1 гыйнварыннан” сүзләре белән алмаштырырга;
- алда күрсәтелгән карардагы 1 һәм 2 кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә):

2. Әлеге карарның көче 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә;
3. Түбәндәге карарны контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары М.Х.Хәбибулловага тапшырырга.

**Җитәкче** **Р.В.Михеев**